Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«11» ноябрь 2019 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән I төркем инвалидларыннан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның толларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Иске Әлмәт торак пунктының 62 нче скважинасы янындагы территорияне төзекләндерү, су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча ремонт эшләре үткәрү.

2) Иске Әлмәт торак пунктында урам утларын ремонтлау һәм яктырткычлар урнаштыру.

Халык җыены рәисе Р.Г. Хисамов

Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов